# ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы «Салагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Салагыш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**01 нче декабрь 2023 нче ел** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның «01» нче декабрендә 9 сәгать 00 минутта һәм 10 сәгать 00 минутта этаплап уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2024 нче елда Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының «Салагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Салагыш торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, укытуның көндезге формасында белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларында һәм иректән мәхрүм итү урыннарында хезмәт итүгә чакырылган затлардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (хәрби хезмәткәрләр контракты буенча, мобилизованныйлар) һәм аларның гаилә әгъзаларын (әти-әниләре,тормыш иптәшләрен, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итеп, яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Совет урамына вак таш сатып алу һәм җәю,торак пункт урамнарын кардан чистарту, дизель ягулыгы һәм май сатып алу, килешү буенча тракторчының эшләре өчен түләү).

2. Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау һәм электр энергиясен җиһазлар (электр товарлары һәм урам яктырту лампалары сатып алу) тапшыруны гамәлгә ашыру.

3. Халыкны су белән тәэмин итү (ремонт, хезмәт күрсәтү, тирәнлек насослары, материаллар һәм су белән тәэмин итү өчен башка хезмәтләр).

« РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 292 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 153 кеше, бу 52,3 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

“РИЗА” позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 153 кеше тавыш бирде;

"КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының «Салагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Салагыш торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. 2024 нче елда Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының «Салагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Салагыш торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, укытуның көндезге формасында белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларында һәм иректән мәхрүм итү урыннарында хезмәт итүгә чакырылган затлардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (хәрби хезмәткәрләр контракты буенча, мобилизованныйлар) һәм аларның гаилә әгъзаларын (әти-әниләре,тормыш иптәшләрен, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итеп, яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертергә .

3. Түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәгеләргә җибәрергә:

1. Салагыш торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Совет урамы юлларына вак таш сатып алу һәм җәю;
- торак пункт урамнарын кардан чистарту;
-МТЗ-82 тракторы өчен май, дизель ягулыгы сатып алу;
- шартнамә буенча тракторчының эшенә түләү.

2. РФ кануннарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүнең Салагыш торак пункты чикләрендә оештыру:

-халыкны су белән тәэмин итүне оештыру (Салагыш торак пунктында су белән тәэмин итү өчен тирән су насосы һәм материаллар сатып алу, ремонтлау һәм башка хезмәт күрсәтүләр).

3. Салагыш торак пункты территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә торак пункт территориясен төзекләндерүне оештыру:

- урамнарны яктырту өчен лампалар, фонарьлар сатып алу, аларны урнаштыру.

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://agryz.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5. Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен әлеге карарны җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Муниципаль берәмлек башлыгы М.М.Мөхәммәдиев